ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2024 ел, 23 сентябрь N 219

"Апас шәһәр тибындагы поселогы"муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының 2021 елның 11 октябрендәге 65 номерлы карары белән расланган "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.3.Планнан тыш күчмә тикшерү, 248 - ФЗ Федераль законының 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклардан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

4.7.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7.8.Рейд тикшерүе, 248 - ФЗ Федераль законының 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-6 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә уздырылган очраклардан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

4.9.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4.Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ Федераль законының 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (pravo.tatarstan.ru).

"Апас шәһәр тибындагы поселогы"

муниципаль берәмлеге башлыгы,

Апас шәһәр җирлеге Советы Рәисе А. Г. Җиһаншин